КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 октябрь г.Казань № 905

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 21 ноябрь, 890 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 21 ноябрь, 890 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гаризаларны формалаштыру һәм җибәрү юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсешен планлаштыру һәм оештыру;

дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре утырышларын планлаштыру, шулай ук алар буенча тиешле документларны рәсмиләштерү;

вакантлы вазыйфаларны биләүгә һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнарында кадрлар резервына кертүгә дәгъва кылучы затлар өчен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә квалификация имтиханы һәм аттестация уздырганда тест үткәрүне оештыру.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Система түбәндәге эшләп торучы ярдәмче системалардан тора:

«Кадрлар составы»;

«Кадрлар исәбе»;

«Оештыру структурасы»;

«Реестр»;

«Кадрлар резервы»;

«Хезмәткәрләрне бәяләү»;

«Укытуны планлаштыру»;

«Җитәкче мониторы»;

«Белешмә мәгълүмат»;

«Персоналлар һәм оешмалар»;

«Хисаплылык»;

«Җитәкче состав»;

«Тикшерүдә тоту һәм хәбәр итү»;

арадаш системалар белән интеграцияләнү;

«Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар»;

«Комиссияләр»;

«Тестлаштыру»;

«Хезмәткә түләү»;

административлаштыру;

журналлаштыру;

мәгълүмат иминлеген тәэмин итү.»;

9.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Системада шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның конфиденциальлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү;

Ссистемадан файдаланучылар турында мәгълүматларны исәпкә алу;

Системаны эшләп бетерүне контрольдә тоту.»;

10 пунктның беренче абзацына «

мәгълүматны һәм шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендә бүтән норматив хокукый актлар белән.» сүзләрен өстәргә;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Система түбәндәге мәгълүмат системалары (алга таба – мәгълүмат алмашуда катнашучылар) белән үзара хезмәттәшлек итә:

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 3 мартындагы 256 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләре турында мәгълүмат тапшыру өлешендә»;

«Татарстан Республикасы Электрон хөкүмәте» - Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтләрен биләүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук аларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр; Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте яисә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә карата һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмат, шулай ук аларны билгеләргә мөмкинлек бирүче белешмәләр урнаштырылган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтларның адреслары турында белешмәләр бирү өлешендә;

«Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисап системасы - Татарстан Республикасы ведомстволары хисапларын кертү өлешендә;

«Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» - Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәр эшли торган дәүләт органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме турында мәгълүмат бирү өлешендә.

Системаның мәгълүмат алмашуда катнашучылар белән мәгълүмати һәм технологик хезмәттәшлеге аларны программа инфраструктурасы һәм технологик инфраструктура ярдәмендә интеграцияләү, мәгълүмат алмашуда катнашучылар һәм техник оператор арасында мәгълүматлар алмашуның килештерелгән форматлары нигезендә электрон рәвештә сораулар җибәрү һәм җаваплар алу ярдәмендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин